**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР
№ ____

Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24, 28 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, район Уставына, Актаныш районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы авыл җирлекләренең Генераль планнарын эшләү турында» 2021 елның 23 апрелендәге ПР-73 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. «Актаныш таңнары» газетасында ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны бастырып чыгарырга.
4. Ачык тыңлауларны үткәрү срогын 1 көн дип билгеләргә.
- ачык тыңлаулар уздыру вакыты - 2023 елның 01 декабре:
- үткәрелү урыны: 10.00 сәгатьтә, Иске Урьяды авыл клубы, Совет ур., 23 нче йорт;
- үткәрелү урыны: 12.00 сәгатьтә, Адай авылы, Горький ур., 2 нче йорт;
- үткәрелү урыны: 14.00 сәгатьтә, Күҗәкә авылы, Совет урамы, 28 нче йорт.
5. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы А.К.Галиәхмәтовны ачык тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
6. Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен, кушымта нигезендә расларга.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
___ _______ 2023 ел,
кушымта

Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге Тәртип Күҗәкә авыл җирлегенең генераль планы проекты (алга таба Генераль план) турында фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатыннан эшләнгән һәм авыл җирлеге гражданнарының Генераль план проекты буенча фикер алышуда катнашу тәртибен, шулай ук Генераль план проекты буенча халык фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Генераль план проекты буенча гражданнарның фикер алышуда катнашуы халыкның Генераль план проекты буенча ачык тыңлауларда катнашуы һәм авыл җирлегендә яшәүчеләрнең язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Җирлекнең генераль планы проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Җирлекнең генераль планы проекты материаллары белән танышу вакыты: дш.- җм: 9.00 - 16:00 гә кадәр, (төшке аш 11.30 - 13.00 гә кадәр).

4. Генераль план проекты территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында fgis.economy.gov.ru рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

5. Җирлекнең генераль планы проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү түбәндәге адрес буенча гамәлгә ашырыла: 423740, ТР, Актаныш ав., Ленин пр., 17 й., Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, инфраструктур үсеш бүлеге;

6. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру, шулай ук Генераль план проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны ачык тыңлаулар уздыру өчен җаваплы кеше башкара.

7. Генераль план проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документаль тәэмин итүне ачык тыңлаулар секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы секретарь тарафыннан ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәү башкарыла. Теркәлү битендә ачык тыңлауларда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- докладчыга төп доклад өчен 20 минуттан артык бирелми;

- җирлекнең Генераль планы проекты буенча фикер алышу өчен чыгышлар 3 минуттан артык түгел;

- репликалар һәм кисәтүләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

11. Ачык тыңлаулар уздырганда секретарь тарафыннан Генплан проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып барыла. Беркетмәне ачык тыңлаулар оештыручысы һәм секретаре имзалый.

12. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар уздырган көннән соң 2 көн эчендә ачык тыңлаулар йомгаклары буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләнең атамасы;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

14. Бәяләмәгә ачык тыңлауларны оештыручы имза сала һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Актаныш таңнары» газетасында, районның рәсми сайтында, Күҗәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында мәҗбүри рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.